

Атюрьево районы ЗАГСында тантаналы рәвештә яна 2023 нче елда туган беренче баланы котладылар.
Нижний Пишляй авылында гомер итvче Бикаевлар гаиләсендә 2023 нче елнын 9 январенда икенче бала буларак беренче тапкыр доньяга аваз салган малайга матур иттереп Ильяс дигән исем кушканнар. Бу борынгы татар иseме: Боек пәйгамбәрләрнен берсе шулай аталган (гарәп теленнән «Алла куәте» дигәнне анлата).
Ильяснын беренче тантанасында Атюрьево районы житәкчесе С.Е.Ермолаев белән ЗАГС нәчәле О.П.Атманзина, мәгариф бvлеге житәкчесе С.Ф. Сятишева ихластан котлаганнар һәм гаиләгә бvләкләр дә тапшырганнар.      Сабыйга район хакимияте бvлеге (ЗАГС) начальнигы Олеся Петровна Атманзина тантаналы котлавыннан башланды:
- Бvген без Россия Федерациясенен кечкенә гражданинын, 2023 елда Атюрьево районында туган һәм теркәлгән беренче баланы хормәт-либез.
Балалар - гаиләнен топ байлыгы, ботен дәvләтнен хәзинәсе. Шундый шатлыклы вакыйга унаеннан, традиция буенча, яна туган сабыйны хормәтләv тантанасы уздырыла. Бикаев Ильяс Владимирович исемен туу турындагы актнын беренче язмасы тозелде. Актлар язу юбилей китабына кул куюнын мактаулы хокукы баланын әнисенә бирелә.
Бәйрәмгә илебезнен яна гражданины хормәтенә янгыраган Россия Федерациясе Гимны аерым тантана бирде.
Кунакларга сәламләv сvзе белән район башлыгы Сергей Егорович Ермолаев морәжәгать итте, ул тантанага килгән яшь ананы һәм барлык туганнарын яна гражданин һәм районда яшәvче тууы белән котлады һәм Гvзәл Фәрит кызына чәчәкләр белән яна туган Ильяска, анын энесе Исламга бvләкләр тапшырды.
Гаиләне бала туу белән мәгариф бvлеге житәкчесе Светлана Федоровна Сятишева да котлады:
- Безнен районда баланын ижади һәм физик vсеше очен барлык шартлар да бар: балалар бакчалары, мәктәпләр, боз аренасы, мәдәният йорты, - дип ассызыклады ул, аннары районнын яна кешесенә балалар бакчасына символик юллама тапшырды.
ЗАГС хезмәткәрләре әзерләгән бәйрәм программасы кызыклы vткән: музыка, анын фонында чара, малай иseме очен сайланган исемнен мәгънәсен ачу, хәтта булачак

һонәренен шаян фаразлавы, шулай ук әбиесе Хәмидә Ималетдин кызы очен сораулар конкурсы да. Ә бәйрәм азагында яраткан баланы тәрбияләvнен мәрхәмәтле рецепты тәкъдим ителгән.